ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Әлдермеш авыл җирлегенең
Сая авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

6 декабрь 2021 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 6 декабрендә 19 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. " 2022 елда балигъ булган һәр гражданнан 500 (биш йоз) сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы? Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлегенең Сая авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүчеләрдән алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга:

а) поселок эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;

б) элегрәк җирләү урыннарын карап тотуга (агач кисүгә, чүп-чар чыгаруга) юнәлдерелгән 2021 елда үзара салым акчаларын Сая торак пунктында спорт мәйданчыгын төзекләндерүгә (яктырту, мәйданчыкны тигезләүгә, Сая авылында поселок эчендәге юлларны карап тотуга һәм ремонтлауга (яктырту, мәйданчыкны тигезләүгә) юнәлдерү;

в) Яшьлек урамында ясалма тигезсезлекләрне төзекләндерү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 273 (ике йоз җитмеш өч) катнашучы кертелгән, 140 (йоз кырык) кеше тавыш бирүдә катнашкан, бу 51,3% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә билгеләнде:

халык җыенында 140 (йоз кырык) катнашучы «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлегенең Сая авылында халык җыены булып узды, Халык җыенының нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. 2022 елда үзара салым акчасын Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлегенең Сая авылы территориясендә

яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 сум (биш йоз) күләмендә кертергә. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

а) поселок эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;

б) элегрәк җирләү урыннарын карап тотуга (агач кисүгә, чүп-чар чыгаруга) юнәлдерелгән 2021 елда үзара салым акчаларын Сая торак пунктында спорт мәйданчыгын төзекләндерүгә (яктырту, мәйданчыкны тигезләүгә, Сая авылында поселок эчендәге юлларны карап тотуга һәм ремонтлауга (яктырту, мәйданчыкны тигезләүгә) юнәлдерү;

в) Яшьлек урамында ясалма тигезсезлекләрне төзекләндерү.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Н.А.Усманов